РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» июня 2019 ел г. Альметьевск № 1122

Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
2015 ел 31 декабрь № 1581
«Әлмәт муниципаль районы гомуми
белем бирү учреждениеләрендә
укучыларның туклануын оештыру турында»
гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Укучыларны кайнар ризык белән вакытында тәэмин итү максатыннан

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2015 ел 31 декабрь № 1581 «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыру турында» гы карарына (2017 ел 30 октябрь № 1756, 2018 ел 30 март № 425, 2019 ел 10 апрель № 730 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бер укучыга ата-аналар түләве суммасын билгеләргә:

- шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләре көненә 22 сум 60 тиен;
- авыл гомуми белем бирү учреждениеләре көненә 12 сум 60 тиен;
- озайтылган көн төркеменә йөрүче гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә туклану көнгә 16 сум 00 тиен;
- гомуми белем бирү учреждениесенең кадет сыйныфларында көненә ике тапкыр туклану 53 сум 60 тиен»;

карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бер укучы өчен туклану бәясен бер көнгә:

- шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләре өчен көненә 30 сум 00 тиен;
- авыл гомуми белем бирү учреждениеләре өчен 20 сум 00 тиен;
- гомуми белем бирү учреждениесенең кадет сыйныфлары өчен көненә 61 сум 00 тиен»;

1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Укучыларны тукландыру көненә җирле бюджет акчасы хисабына 30 сум 00 тиен исәбеннән оештырыла;

Зак. № 3063

- гомуми белем бирү учреждениесенең кадет сыйныфлары өчен 61 сум 00 тиен».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны«Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 сентябреннән барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район башкарма
комитеты җитәкчесе М.Н.Гирфанов